# КАРТ ЯЛЧЫ

## I

Ул елны ике читенлек бергә җыелды. Ашлык искиткеч уңган иде. Шуңа үч иткән кебек, көз бик иртә килде, ничаклы тырышсак та, көннәр корырак чакта игенне ындырга кертеп бетерергә өлгерә алмадык.

Сентябрьнең ахырлары җитеп килә, бу вакытта башка елларда ындырың зур-зур кибәннәр белән тулган була; син шуларга карап, күңелләнә-күңелләнә, суык кышны каршы алырга хәзерләнә башлыйсың.

Ягарга утын китерәсең, өйләрне әйбәтләп ябасың, сылыйсың, ишек, тәрәзәләрне төзәттерәсең, җылы тотсын өчен, яхшылап эргә саласың, арбаларны ныгытасың; тары, карабодай кебек, көзге өлешкә дип чәчелгән ашлыкларны сугып, келәтнең өсәкләрен тутырасың. Аның өстәвенә алу-салу өчен, өй кирәк-ярагы өчен бер-ике йөк ашлык белән калага да барып кайтасың.

Көн-төн эшлисең, җаның рәхәтләнә, аруның нәрсә икәнен дә белмисең.

Ә бу ел... бу ел... ят та үл.

Бөтен басуны, әрәмгә бирелгәндәй күп булып, иген чүмәләләре тутырып утыралар. Ай буена өзлексез яуган яңгыр аларның төпләренәчә үткән — көлтәнең өсте үрә, төбе чери. Җитмәсә тагы мал чыгып та бик харап итеп бара.

Аермадан бирерәк ике җир бодай бар иде. Ходайның кодрәтенә[*] исең китәр, шулай шәп булып үскәннәр, бу ел арыш икмәге капмабыз, бодай гына ашап чыгарбыз, дип шатланышып тора идек, мал аңар да җитеп бара.

Берничә мәртәбә тотып алып кайткан идек, аннан да файда чыкмады. «Хәерсезләр, минем сыерларны тотып алып кайткансың икән; балалар сөтсез утыра, чыгарып җибәр әле», — дип, бик җиңел генә алып китмәкче булалар. Тот капчыгыңны, акылың алтын икән, ахак кебек бодаемны таптат та, мин сиңа буш кына биреп җибәрим имеш. «Балалар сөтсез утыралар!» Сөт кирәк булса, кеше игененә чыгармассың, карарсың!

Сыеры артыннан мужик бер килә, ике килә, һаман да бирмәгәнеңне күргәч, үзеңне эт урынына сүгә дә:

— Мәңге асрый алмассың әле! — дип кайтып китә. Бер көн тотасың, ике көн тотасың, сыерның эчләресуырыла, күргән саен күзләрен мөлдерәтеп: «чыгар мине!» дигән кебек ялбарып карый.

Аптырагач, иясенең түләп алуыннан өмет өзгәч, сыерны кызгана башлыйсың, ахырда:

---

[*]1934 елгы басмада бу урында *Ходайның кодрәтенә* сүзләре төшерелеп калдырылган.

— Бу хайванның ни гөнаһсы бар? Аны ач тотып ни файда? — дисең дә чыгарып җибәрәсең.

Шулар белән борчылып, җаныңны кая куярга аптыравың җитмәгән кебек, тагы бөтен нәрсәсе сиңа каршы төшә. Кояш рәтләп чыкмый. Күк йөзе куе соры болытлар белән каплана. Болар, тау башларына тиеп-тиеп үткән кебек, түбәннән бертуктаусыз агалар. Азрак ачылды бугай дип, атыңны җигеп чыгарга өлгерә алмыйсың, нечкә иләктән сибәләгән кебек, вак кына яңгыр ява башлый.

Яуса явар, яланда калганчы, ындырыңда чересен, дисең дә, болытына, яңгырына карамастан, атыңны арытып, арбаңны, збруеңны вата-вата, шул пычракта ташый бирәсең...

Әле дә ярый, атлар таза, аларның алдыннан солыны өзмибез. Барганда да, кайтканда да, бушаткан-төягәндә дә көлтәдән башларын алмыйлар.

Башка вакыт булса, мондый явым-чәчемле көндә ат ашатып, збруй төзәтеп өйдә ятасың. Ә бу ел атны хәл алдыру кайда, көннең пычраклыгына карамастан, туктаусыз чабасың гына. Башка вакыт көненә дүрт-биш юл бара торган булсак, хәзер басу артындагы җирләрдән алтышар-җидешәр урыйбыз. Шулай булса да атай карт канәгатьләнми. Син чыланып, эштән чыгып кайтасың, ул, хәл сорашып, безгә булышу урынында, ачулы йөз белән каршы чыга да, озын кашларын салындырып:

— Йөрисез шунда ат этләп! Ныграк төяргә кулыгыз черегәнмени?! Әллә анда баргач йоклап ятасызмы? Сез бер юл кайтканчы Җамали малайлары икешәр урыйлар!.. — дип сукрана башлый.

Картлар белән талашып торуны яратмыйм. Юкка сүз әрәм итү була. Аның сукрануына җавап та бирмичә, сикереп кибән башына менәм; энем көлтә бирә, күз ачып күз йомганчы, дүрт-биш арбаны бушатып та ташлыйбыз; куенга бер кисәк икмәк белән берничә бәрәңгене кыстырып, тагын чыгып чабабыз.

Әни, бичара, безне кызганып, самавырын куеп көткән була. Үзенчә, өшеп, күшегеп кайткан улларын чәй белән җылытып җибәрмәкче. Әтинең ачулы йөзен, салынган кашын күргәч, ул да эчтән тына, чәйгә керегез-фәлән дип әйтергә курка.

Чәй кайгысы түгел әле, ничек кенә булса да тизрәк ташып алырга кирәк. Туры килсә, аягүрә генә бер-ике чынаякны аударасың, булмаса, шул икмәк, бәрәңге белән дә бик шәп йөрисең.

Туктаусыз чабудан, йокысызлыктан, яңгырдан бер дә кеше төсе калмады. Өс-баш пычрак, күшегүдән йөз күгәреп, сары җон белән капланган.

Юлларның начарлыгын әйтергә дә юк: пычрак, тайгак, күперләр бозык, юл саен диярлек камыт бавы, тәҗе өзелеп, арба ватылып теңкәңне корыта,

Тау як көлтәсе бигрәк җанга тия. Анда юллар тигезсез, чокыр-чакырлы. Арбаң аз гына кырын килсә, чана кебек тыз-тыз итеп, тау асты ягына таба китә башлый. Без, бернәрсәгә дә карамастан, һаман чабабыз гына.

**II**

Син ашыкканда ул кабалана, диләр.

Ашау-эчүеңне онытып, берүзең кырыкка ярылырдай булып йөргәндә, энем арба башыннан егылып төшеп уң кулын имгәтте.

Сынганга ошамый, шулай да кара янып күгәреп чыккан, бераз шешенеп тә бара. Үзе, кулының имгәнүенә карамастан, барырга теләсә дә, мин якын килмәдем:

— Дөнья куам дип чулак булып калыр хәл юк инде; үзем дә ташырмын әле, кулы әзрәк төзәлгәнче өйдә ятсын!

Берүзем дүрт ат белән кичкә каршы көлтәгә барырга булдым. Марҗа басуындагы солыга күрше малы кереп, харап итеп бара. Бүгеннән калдырмый шуларны алып кайтырга кирәк.

Яңгыр яварга чамалап тора. Башка вакытта: «Аз төйисез, акрын йөрисез!» — дип сукранган атай бүген нидәндер бераз йомшарган күренә.

— Атларың да бик өшәнгән, якындагы солыга гына барырга кирәк иде, — ди.

Мин аңа карамадым, фурманга аягүрә бастым да, ут чыккан кебек, чаптырып чыгып киттем.

Безнең атлар начар түгел: таксаң да, буш җибәрсәң дә, бер дә арттан калмый баралар. Энем капкадан чыгаруга:

— Әйдәгез, малкайлар! — дип бер кычкырдым. Шуның белән һәммәсе, җепкә таккан туплар кебек, минем арттан тезелеп очалар гына.

Барачак җирем алты чакрымнар булыр. Мин киткәндә атай карт икендегә тәһарәт ала калган иде. Ахрысы бик артык шәп каулаганмындыр: кояш та батып өлгермәде, мин солыга килеп җиттем. Элекке заманның арбалары булса, эш озакка тартылыр, бер кеше төяп, бастырыклап беткәнче, әллә ничаклы вакыт үтәр иде; хәзерге фурман арбаларга көлтә төяве — бу уен гына.

Килеп тә җиттем, күз ачып, күз йомганчы дигәндәй бер арада дүрт арбаны төяп, кайтыр юлга да чыктым. Атларны кызганып, шунда кунарга да уйлаган идем, төн ягыннан явып килгән төсле күренгән кара болытлар куркытты; яуса, көлтә юешләнеп, эштән чыга. Кайтсаң, ичмаса, бушата алмасаң, бер ышык җиргә кертеп куярсың.

Кайтуы кайту инде, анысы — өйрәнгән эш. Юлымда «Яманташ» дигән бер тауны[1+] үтәсе бар. Моннан мендерү көн коры чакта да бик җиңел булмый. Хәзерге кебек явым-чәчемле вакытларда бу инде сират кичүдән бер

дә ким саналмый.

**III**

Бүген төштән соң яумады. Шуңа күрә мин, юл бераз сүрелгәндер, атлар акрынлап мендерсәләр кирәк дип, үземне юатыбрак килә идем, эш мин уйлаганча барып чыкмады.

Мин тауга килеп җиткәндә, анда инде бер көтү халык арбаларын мендерә алмыйча газаплананалар иде. Садыйк мәзин малае Вәликәй өч аты белән килеп капкан. Бу — авылда атларының яхшылыгы белән исем чыгарган кеше. Аның алдында тагы байтак атлар бар. Һәммәбез җыелып, алдагы атларны берәм-берәм мендерешеп озаттык. Нәүбәт Вәликәйгә килде.

Мин аның атларының җиңел алып менеп китүләренә бик нык ышанган идем; көн-төн көлтә ташу белән бераз өшәнгәннәр ахрысы, малкайлар: башта каулап карадык, алай булдыра алмагач, яннарыннан булыша башладык. Юк, эш чыкмый.

Арада Әхми байның ялчысы Шаһи карт та бар иде. Бабай атларының арбаны тартырга тырышып та кире артка таеп-таеп китүләренә карап торды да:

— Вәликәй, кая соң синең кара атың?! Ул мендерер, — диде.

Егет кулы белән өченче арбага күрсәтте:

— Ул артта шул!

Бабай үзенекен куймады:

— Бар, кара атыңны тугар да, менә бу алдагы арбага китереп җик, ул мендерер, — диде.

Арбалар тау астына таба кирегә тәгәрәп китмәсеннәр өчен, тәгәрмәч асларына агачлар кыстырдык, тиз арада кара атны алдагы арбага китереп җиктек.

Ну, көч бар икән соң малның үзендә! Җигеп, «наа...а!..» дияргә өлгерә алмадык, кара тимер «әһ» тә димәде, арбаны җилтерәтеп алып менеп китте.

Шаһи карт тирән бер горур белән:

— Әйттем бит мин сезгә! Бер тартуы мең сумлык бар бу малның! Гәрәй карт бияләренең баласы шул ул! — диде.

Без кара атны икенче арбаларга җигеп маташканда, Шаһи бабай Гәрәй картның атаклы ак бәкәл бияләре, аларның шәплеге хакында хикәя сөйләп алды.

Үзенең өч арбасын мендергәч, Вәликәй атларын яңадан җикте дә кайтып китте.

Ул: «Сезнең арбаларны да мендертик!» — дигән иде, бабай бер дә якын килмәде:

— Беләм мин синең мәзиненңне! Ул — мәзин түгел, мукшы ул, саран

мукшы! Әле дә, ни эшләп болай соңга калдың, дип җаныңны алыр. Бар, тукталма, без үз көнебезне үзебез күрербез, — диде.

Мин дә шуңа кушылдым: кара ат көчлесен көчле, шулай да бит, көчле дип, бөтен авылның көлтәсен анардан тарттыру килешми инде. Шаһи картныкы — ике, минеке — дүрт. Боларның барлыгын бер кара атка өстерәтү — бу инде бер дә ярамый.

Минем үземнең «Ахун» исемле зур туры атым бар. Ул Вәликәйнең карасына бирешмәс дип уйлыйм. Мендерә алмыйлар икән, яланда куну да бит күрмәгән эш түгел.

Вәликәй киткәч, үзебезнең атларны кузгата башладык. Алда Шаһи картныкылар, аның атлары бик йончу. Шулай булмый ни эшләсен, ялчы кулындагы ат әллә кая китә алмый инде. Аның бае Әхми бик саран нәрсә. Атларга бер солы көлтәсен артык биргән өчен дә дөнья чаклы тавыш куптара торган адәм. Бу атларның мендерүләренә күңелем җитми. Шулай да, ятып калганчы атып кал дип, атларны кауларга тотындык. Аркалыкларын төшергән булдык, яннарыннан тартышып карадык. Юк, булмагач булмый инде. Безнең акырып-бакырып һайдалавыбызга карап, атлар бер генә атлыйлар да таеп тезләнәләр, егылалар, бабайның мендерүгә күп дәрте күренми. Минем димләвем белән аз-маз кузгалса да, бөтен сүзе, торышы белән:

— Барыбер булмый, хайваннарны юкка азаплыйсың! Иртәгә дә көн безнеке бит! — дип тора.

Минем болай тиз җиңеләсем килмәде. Картның ай-ваена карамыйча, «Ахун»ны тугардым да бабайның алдагы арбасына китереп җиктем. Вәликәйнекеннән ким булмады, җигүгә арбаны шатырдатып алып менеп китә башлады.

Фу... каһәр төшсен, саран байның рәтле збруе буламы соң аның!

Җенләндереп инде мендереп җиттем дигәндә, сул як тәже өзелде, аның артыннан сул як тәртәнең әллә нинди җепләр белән генә бәйләп куйган төбе ычкынды да, арба көлтәсе-нисе белән тау астына очты. Әле дә ярый, кендек буш икән, юкса минем атны да өстерәр иде.

Мин әрнүемнән:

— Чукын, җәһәннәмгә кит! — дип сүгенеп калдым. Карт, бер дә исе китмичә, аптырамыйча, бик озын сузып, мине шелтәли башлады:

— Әйттем бит сиңа, юк белән маташасың, Сәфәр... Яшьлегеңә барасың!..

Инде ни эшләргә? Карт белән җаваплашып вакыт үткәрү ярамый.

— Ярый, бабай, эш синеңчә булды! — дидем дә, атларымны юлдан бер як читкәрәк чыгарып тугара башладым.

Төн караңгы; мондый вакытта әллә кая чокырга очкан арбаларны чыгарып маташмассың бит инде. Безгә шунда кунарга туры килә.

Үлән бик шәп, атлар рәхәтләнеп ашасыннар. Кара бия бик йөремтәл нәрсә, ничаклы кыска тышауласаң да, ничаклы ач булса да, аяк астындагы үләнгә карамыйча, әллә кая китә. Аның артыннан башкалар да иярәчәкләр. Кунарга дип чыкмаганга, минем тышавым да, кешәннәрем дә юк икән... Инде моңа гына калса, бер чарасы табылмый булмый: нукталарның тезгеннәрен алдым, тышау да чыкты, кешән дә булды.

Эшне бетереп арбалар янына килсәм, Шаһи бабай бер атын да тугарып бетә алмаган әле.

— Нихәл, бабай? Нишләп син болай озак маташасың?

Карт ялчы кемгәдер, нәрсәгәдер рәнҗегән тавыш белән:

— Сөйләмә инде, Сәфәр балам, бер картайгач юнең китә икән ул... Җирән биянең чөйлек бавы чияләнгән... Сүстән ишкәннәр икән, яңгыр белән бүртеп беткән... — дип сукранды.

Никтер картны кызганып киттем. Әхми бай да, Алладан курыкмаса, адәмнән оялырга кирәк иде. Шундый пычрак вакытта, кара төнгә каршы, әлҗерәп беткән җитмеш яшьлек картны көлтәгә җибәрергә ярыймы соң! Ичмаса, аты-арбасы адәм рәтле булса тагын бер хәл иде!

Сорамыйча-нитмичә үк бабайның камытына килеп тотындым.

— Кая, бир әле, үзем карыйм!

Бабай аптырап чигенде. Минем тагы ачуым килде: чөелдерек дигәне — әллә нинди нәзек җепләр белән урап, чуалып беткән бер нәрсә. Мондый яңгырлы төндә түгел, көндез дә очын табар хәл юк.

— Бабай, мин кисәм моны! — дидем. Карт аптырый төште:

— Иртәнчәк ничек юнәтербез икән соң? Мин аңа карамадым, тоттым да кисеп җибәрдем. Тиз арада икенче аты да тугарылды.

Картлар сак була бит; аның фурманында ике тышавы бар икән. Бабай шуларны алды да:

— Минекеләр китмиләр, үлән булса, ябырылып яталар, — дип, атларын озын гына тышаулап җибәрде.

Атларның кайсы якка таба юл тотканын чамалар өчен бераз карап тордык та, арбаларыбыз янына килдек. Төн караңгылана бара, болытлар куера, көзге вак яңгыр акрын, ләкин туктаусыз һаман сибәли иде.

Минем оек-чабатам эштән чыгып пычранган, эченә су тулып, лаштырдап тора. Өстемдә камзулдан башка һичнәрсә юк, ул да актык җебенәчә юешләнгән. Мин боларны моңарчы эш кызуы белән сизмәгәнмен икән. Арба янына килеп, яту, йоклау хәстәрен күрә башлагач, мине бизгәк кебек калтырау алды.

Беребездә дә шырпы да юк. Ул булса ичмаса, корырак көлтәне ягып, бераз җылыныр идек, башкача җылыну өмете өзелде. Арбаның төбеннән корырак көлтәләрне тартып чыгардым да, иң элек дер-дер калтыраган картны шулар белән күмеп ташладым. Аннан соң үзем шулар эченә урандым.

Юеш камзуллар, юеш оеклар салам астында бераз җылына башлады.

Йокларга уйлыйм. Бабай исә нидәндер йоклый алмый. Башта нәрсәдер сорады, аннан соң миңа таба әйләнеп ятты. Картны үзем белгәннән бирле күрә килсәм дә, аның белән болай якыннан очрашканым, озаклап сөйләшкәнем юк иде. «Яманташ» тавы картны миңа бөтенләй танытты.

**IV**

Һәр атнаның дүшәмбесендә кайнап, шаулап тора торган зур базары һәм иген, мал, урман кәсебе аркасында күрше авыл халыкларын үзенә җыйган, атаклы байлары белән тирә-якта дан тоткан Өлкән авылның биек йортларыннан, тук, шәп аргамакларыннан, куәте белән һәммә нәрсәне басып, изеп барган байлыктан куркып, кысрыкланып, читкә, күпер башына җәберләнеп, чыгарылып ташланган мескен бер балчык өйдә чабатачы Шәмси бабай белән җон эрләүче Гайни карчык үзләренең һаман бер төсле, һаман тыныч, шау-шусыз гомерләрен үткәрә булганнар.

Үзләре белән яшьтәш балчык өйләрен һәр көз әйбәтләп сылыйлар. Якын урманнан кипкән агачны бергәләп, аркаларына күтәреп, җәйдән үк ташыйлар, киртә буендагы тарыларын бергәләп барып уралар, аны кыш буена, аяз көннәрдә кием җәеп кенә, көлтәләп сугалар — шулай рәхәт кенә яшиләр икән. Бай булмаганнар, аны уйламаганнар да, аңа тырышмаганнар да: Ходай ни бирсә, шуңа риза булып гыйбадәт кылганнар.

Карт кыш көне чабата тукый, аркан, дилбегә ишә; җәй көне озын кармак сабын күтәреп балыкка йөри; шуның белән чәй-шикәрлек таба. Гайни карчык байларга җон эрли, киләп сара[1]; берәр җиргә китсәләр, йортларында кала; моның өчен аз-маз он, катык, сөт ала; — шулай гомер итәләр.

Ходай аларга дүрт бала бирә.[*] Болардан өчесе үлә, тик төпчекләре — Миңнегөл генә үсә.

Аны кияүгә бирәләр. Ләкин ике елдан соң кызлары үлеп, анардан Шаһибәк исемендә ир бала кала. Кияүләре килделе-киттеле, юаш, юньсез бер нәрсә икән. Хатыны үлгәч, дөньясын, чәчкән тарысын ташлап каядыр чыгып китә — шуннан аның башы югала. Эзләп та таба алмыйлар. Суга батканмы, бер җирдә үлеп калганмы, үзе теләп киткәнме — мәгълүм түгел.

Кияве белән кызының язмышы бу рәвешле булганнан соң, аларның

---

[1] *Киләп сара* – орчыктан махсус җайланмага сарып, чуалмасын өчен бәйләм итеп уралган җеп эшләп бирә.

[*] 1925 елгы басмада бу җөмлә түбәндәгечә: *Аларның дүрт балалары була.*

баласы Шаһибәкне карт белән карчык үзләренә алалар. Үзләренчә кадерләп, иркәләп, актык сыныклары белән сыйлап, баланы үстерәләр.

Шаһибәк сигез яшькә җиткәч, Шәмси карт әҗәл җитеп вафат була. Карчыкка тормыш бик кыенлаша. Ул бөтен авылда хыянәтсезлеге белән бик артык танылган бер әби булганга, байлар аны үзләренә алмакчы булалар.

— Җон, җитен эрләрсең, тавык-чебеш карарсың; өстең бөтен, тамагың тук булыр, — диләр.

Гайни моңа риза булмый: кадерле карты, балалары белән гомер иткән балчык өйне ташлау — мәрхүмнәрнең күңеленә авыр тоелыр кебек була. Янына икенче бер ятим әбине өйдәшкә ала да шунда торып кала.

Көннәре, төннәре бер-беренә охшап акрын гына агалар. Эшләрен дә эшли, гыйбадәтен кыла да, улы Шаһибәкне ияртеп, картының каберенә барып, озаклап елап кайта.

Шәмси карттан калган бер ат сыман нәрсә булса да, карчык аны сатып, акчасын мәрхүмне җирләүгә тота. Аның тик көтү башында йөри торган зур әйбәт кәҗәсе белән мич башыннан төшми ята торган карт мәчесе калган.

Улы Шаһибәк, карт мәче, зур кәҗә, өйдәш әби, карчык үзе — шулай барысы бергә дус кына, тыныч кына гомер итәләр. Сүз күп булмый, булса да иң күп сөйләнгән нәрсә мәрхүм картның яхшылыгы, аның ясаган чабаталарының ныклыгы, теге югалган кияүнең, ахмаграк булса да, бик изге җанлылыгы хакында була.

Карчыкның күзләре, куллары, Ходайга шөкер*, әле сәламәт булганга, ул артык мохтаҗлык та күрми. Карты үлгәннең икенче елында авылның байларыннан Гаделгәрәй дигән берсе, кеше үтерүдә гаепләнеп, хөкемгә бирелгән икән. Шул, исән-сау котылсам, үзем үлгәнче һәр елны Гайни карчыкка ун таяк тары чәчеп бирермен, дип нәзер әйткән икән; әбинең бәхетенә каршы, котылган һәм, сүзендә торып, карчыкка авылга якын бер җирдә һәр ел ун таяк тары чәчеп бирә булган.

Карчыкның кышлары элекке кебек орчык, каба[1] тирәсендә үтсә дә, җәйнең күбрәге шул тарыга бирелә башлаган. Ул атна саен диярлек, үсәме икән дип, мал кермиме икән дип, барып карый, тары җиренең башына утырып, Ходайдан яңгыр тели, бәрәкәтле иген сорый.

Бераздан аны утый башлый, бераз баш күрсәтү белән, үрдәк-каз тимәсен дип, кечкенә малай төсле итеп куркылыклар куя.

Карчык мондый дөнья эшләре белән генә калмый, үлүен, ахирәтен дә уйлый, аңар да хәзерләнә.

---

*1925 елгы басмада *Ходайга шөкер* сүзләре төшерелеп калдырылган.

[1] *Каба* – җеп эрләү өчен йон, сүс, мамыкны беркетә торган тараклы җайланма.

Әллә кайчан ук аның кәфене алып куелган, кәҗәсен фидиясенә, кара тавыкны гүр садакасына, агын — үзен юган кешегә, бәйрәмнәрдә генә кия торган ак күлмәген үзен кәфенләүчегә бирергә әллә кайчан әйтеп бетергән. Кабер чәчемлеге өчен дип җыйнап килгән ике көмеш тәңкә белән бакырларны нинди кара көнгә төшсә дә тапмаслык итеп әллә кай эчкә яшергән.

Карчыкның дөньясы шулай үтә, үлемгә шулай хәзерләнә.

**V**

Шаһибәк бабасыннан соң әбисе белән ике ел яши. Ул арада аңа ун яшь тула.

Бер җәйне аны авылның байларыннан Байморза тырма тырмалатырга алдыра. Малай юаш, акыллы күренгәнгә, аны кайтармыйлар, еллап хезмәткә яллыйлар. Шаһибәк бер уңайдан Байморзада унбиш ел тора. Яше егерме бишкә җиткәч, бу байның эшләре начарланып, ялчы тотарлык хәле калмый да хәзерге ярлы Әхминең атасына яллана. Хәзергәчә һичберкая китмичә, җәе-кышы шунда ялчылыкта үтә.

Карт бай бик яхшы булган. Шаһибәкне бик яраткан, аны күп вакыт үзе белән йөрткән. Дөрес, кайбер чакта кирәгеннән артык кызып китеп, Шаһибәкне ни очраса шуның белән бүртендергәнче кыйнап ташлый икән, ләкин бу сирәк була. Бай үзе, ахырдан бу эшенә үкенеп, кыйналган ялчыларының күңелен табарга тырыша башлый булган. Аларга якты йөз күрсәтә, хәлләрен сораша, уен-көлке белән сүз куша икән.

Шаһибәккә юмартлыгы да булган, һәр ел, бик зур төятеп, бер арба гошер[2+] бирә, үзенең иске киемнәрен бүләк итә. Һәрбер уразада бер-ике баласының фитырыннан[3+] моңа да өлеш чыгара икән.

Шаһибәк карт бай вакытында шундый кадерлерәк ялчы булып яшәгән. Бай, аның белән генә калмыйча, Шаһибәкнең олыгайганын игътибарга алып, аны йорт хезмәтеннән азат итәргә, тик умарта каравылына гына куярга уйлый башлаган булган. Ләкин, моның бәхетсезлегенә каршы, карт байга әҗәл җитеп, үлеп киткән. Аның бөтен йорты, малы, барлык байлыгы белән бергә Шаһибәк тә мәрхүм байның бердәнбер улы Әхмигә күчкән.

Шул көннән Шаһибәк бабайның тормышында зур үзгәреш була, картка авыр көннәр килә.

Мәрхүм бай, моның картлыгына карап, җиңел эшләргә генә куша, берәр авыр эш тапшыра башласа:

— Әй, син, яшьтәш, кая менә бу эшкә юнең җитәме, булмаса, башка берәрсен кушармын!.. — дип сүз башлый икән. Шулай яхшылап әйткәч, авыр эше дә җиңел булып китә булган...

Ә бусы, бу яшь бай Әхми, атасына бер дә ошамый. Шаһибәкне күп ялчылардан берсе саный, аңа авыр дими, җиңел дими, ни туры килсә шуны куша. «Бабай, нихәл? Бик арып китмисеңме?» — дип сүз дәшү кайда, ул менә бүгенге кебек яңгырлы, пычрак көннәрдә начар атлар, ватык арбалар белән көлтәгә җибәрүдән дә оялмый. Ә карт бай булса, мондый чакларда Шаһи бабай өйдә рәхәтләнеп ятыр, хәл җыяр иде. Бу имансыз Әхми, маңка малай, атасы белән яшьтәш картны башка вак ялчылар белән бер рәткә куя...

Яманташның тайгак юлларыннан атларыбыз мендерә алмау сәбәпле, караңгы төндә яланда бергә кунарга туры килгән карт ялчы — менә шул Шаһибәк бабай иде.

**VI**

Урта буйлы, шадра битле, куй күзле, йомшак, түгәрәк, саргылт сакаллы, турылыгы, буйсынучанлыгы бөтен йөзеннән күренеп торган салмак авыр йөрешле, әз сүзле бу юаш картны мин бала чагымнан ук күрә килдем. Берничә мәртәбә бергә ат та эзләдек. Ләкин озаклап сөйләшмәгәнгә, миңа ул гомер буенча ялчылыкта торган бәхетсез бәндәләрнең берсе булып күренсә дә, ничектер аңа каршы бертөрле якынлык та, кызгану-фәлән дә миндә юк иде.

Мин аны, башкалар кебек, кайчандыр бала булган, уйнап, шаярып йөргән, аннан соң җегет булып яшәгән, инде картайган бер кеше иттереп уйлый алмый идем. Ул, гүя бөтен гомеречә шул бер төстә булган, әйтерсең, шул ертык ак чикмәне, аягындагы хатыннар чабатасы, билендәге чыбыркы, башындагы мөселман бүреге, аксыл-сары сакалы белән дөньяга килгән дә, шул көенчә яшәп, кабергә дә барачак, кыяматтә дә шулай булачак: «Менә Шаһи колың – мин; теләсәң ни эшләт, миңа барыбер!» — дип, Алла каршысына барачак кебек иде.

Авылда һәр кеше бер эше, бер аерым ягы белән телгә алына. Йә усаллык, йә яхшылык, йә үткенлек, йә караклык, суфилык, хәйләкәрлек, — белмим, тагын ниләр.

Ә Шаһи хакында берсе дә юк. Үзе күренмәсә, һичкем һичбер урында аны телгә алып сөйләми. Һичбер эш турында, моны ул эшләр, ул булдырыр, фәлән, дип аны хәтерләми.

Тик әллә кайчан, әллә нинди бер мәҗлестә кемнеңдер аны кызганып:

— Бичара, юньләп бисмилла да әйтә белми, ике гаеттән башка вакытта мәчет ишегенә аяк басканы юк, — дип, бик артык каралыгы хакында сөйләгәне генә колагыма кереп калган.

Бичара берәр җирдә үлеп калса, бәлки шулай онытырлар. Шаһи карт кая булды дип эзләмәсләр дә иде кебек.

Җәйнең аяз, җылы, айлы кичләреннән бере иде. Мин ялгызым гына аттан кайтып килә идем, тирә-якта гаҗәп бер тынлык иде, каршыма бер арбаның якынлап килгәне күренде. Аты өстерәлеп кенә атлый. Арба һаман акрын гына бара. Кемдер үрәчәгә яны белән яткан да атның ялкау гына атлавы уңаена ниндидер озын көйгә тирән эчке бер тавыш белән моңаеп бара. Бу моң туры йөрәгемә төште: «Син кем?» — дип дәшергә телем бармады, баскан җиремдә катып калдым.

Җирәнчеккәй атның, ай, ялларын
Кыйблалардан искән җил тарый;
Үз бәхеткәйләрең, ай, булмагач,
Байга хезмәт итеп кем ярый...

Шул авыр, тирән моң мине басты, үзе дә, ахры, дөньядан югалгандыр, мине күрми үтте.

Җырлап үтүче — карт ялчы Шаһи бабай булган икән.

Шул очрашудан соң миндә әллә нинди бер тойгы уянды, аны күргән саен шул кичә исемә төшә торган булды. Берәр сүз әйтим, күңелен табыйм, дим. Ләкин нәрсә әйтәсең? Ни белән аның күңеленә рәхәт бирә алырсың? Күңел таш түгел бит, уңайсыз бер яктан сүз ачарсың да картның яралы йөрәгенә кагылырсың.

Якыннан күргәндә, дөресен әйтсәм, мин бу картта яралы да, ярасыз да йөрәк юктыр кебек тоям.[*] Еректан күрсәм, теге кичә, теге җыры, моңы исемә төшә дә картның йөрәге яралыдыр кебек бер тойгы, бер кызгану уяна.

Аның йөрәге бардыр, ул яралыдыр, тик аны дөнья баскандыр, һичбер вакыт, һичкем аның хәлен белергә, бергә кайгырышырга теләмәгәнгә, ул үзе дә йөрәгенең барлыгын, аның ярасын оныткандыр, ул бернәрсә дә белми, нәрсә икәнен аңламыйдыр. Йа, Ходай[**], бу карт турында уйлый башлагач, әллә үзем дә саташам инде!..

**VII**

Ничек кенә дисәң дә, дөнья — дөнья инде. Ул сине баса, аның кызу эшләре, мәшәкатьләре күңелдәге әйбәт уйларны оныттыра. Башка һәрбер очравымда карт миндә авыр бер кызгану уята торган иде. Әле бүген энемнең кулы имгәнүе, атайның без кайткан саен кашларын салындырып, ачулы йөз белән каршы чыгуы, яңгырлы төндә Яманташ тавыннан атларыбыз мендерә алмый азапланулары, бигрәк тә бабайның үзенең бүген ничектер җанлырак, булдыклырак кылануы, Вәликәйнең кара аты хакындагы сүзе дөреск

---

[*] 1920, 1922, 1925 елгы басма вариантларда бу җөмлә түбәндәгечә бирелгән: *Якыннан күргәндә, дөрестен әйтсәм, мин бу картта яралы да, ярасыз да йөрәк юктыр кеби, ул җансыз, тик әллә ничек кенә кузгалып йөргән бер нәрсәдер кебек тоям.*

[**] 1925 елгы басмада *Йа, Ходай* сүзләре төшерелеп калдырылган.

чыккач, бераз күтәрелеп, бик чак кына мактанган төсен алуы, — ничектер карт ялчы хакында башка очрауларымда була торган кызгану башта булмады.

Картның тәҗеләре, тәртә төпләре өзелеп, көлтәле арбасы тау астына очкач, мин дүрт атны тугарып, тышаулап, кешәнләп килгәнче бер атын да тугара алмый, чебәләнгән чөйлек бавын чишә алмый азапланганын күргәч, бигрәк тә әллә нинди кызганыч, беткән тавыш белән:

— Бер картайгач булмый икән инде ул... Чөйлек бавын киссәң, иртәгә нишләрбез икән соң... — дигән сүзен ишеткәч, карт тагы миңа теге айлы кичтә авыр моң белән җырлап барган бабай булды. Шул хәлдә арбалар астына килеп, аны коры көлтәләр эченә күмеп ташлагач, ул инде миңа бигрәк мескен булып күренә башлады.

Яңгыр сибәли, төн бик артык караңгы... Юеш кием, суык һава йоклатмый.

Карт үзе сүз башламагач, мин аңар:

— Нихәл, бабай? Яшь бай үзеңә бик каты түгелме? — дигән идем, ахры авырткан җиренә кагылганмындыр: җавап бирмичә үк, миңа таба борылып ятты, башка вакыттагыга бер дә ошамаган рәвештә сүзгә ачылды. Әйтерсең, ярага чәнечтеләр дә, аннан кан китте.

Кеше шулай бит. Ничаклы беткән кебек, юньсез кебек күренсә дә, дөнья ничаклы басып, изеп җанын үтерсә, йөрәген капласа да, кайбер вакыт, яңлыш бер ярасына кагылсаң, аның үлгән җаны терелә, сүнгән йөрәге тибә башлый. Бабайга да шулай булды бугай.

Мин, яшь бай, фәлән-төгән дип, сүз юктан гына әйткән идем, ә шул аның әллә кая төпкә батып, онытылып беткән уйларын тергезде, аңа җан бирде.

— Сөйләмә инде, Сәфәр туганкай... Борынгы картлар юк инде алар... Карт бай мине яшьтәш дип аркамнан гына кагып йөртә иде. Бусы бик һавалы нәрсә... Әйтергә җиңел бит, бу бит минем кулымда туды... Мәрхүм бай беркөн мине чакырды да: бар әле, яшьтәш, ди, минем хатын балаларга итә бугай, Фәрхи карчыкны чакырып кил әле, ди. Аягым җиргә тимәде, бер минутта Фәрхине китереп җиткердем... Көн буе анда чаптым, монда чаптым... Әллә кемнәрдән сөенче алып беттем... Үсә башлагач та уеннар ясап бирдем. Тартып, күтәреп йөреттем, чыбыркы иштем. Хәер, яшьли үк бик явыз нәрсә иде инде... Бабай, мине күтәреп йөрт дип муеныма атлана иде дә, авыртамы, авыртамы дип, колакларымны тешләп җәфа чиктерә иде... Карт байга сүзем юк... Мин кергәндә байлыгы чамалы иде... Бик нык эшләдем үзенә... Мәрхүмнең, үлгәнче, бу йортларда, бу атларда, бу арбаларда Шаһибәкнең көче бар, хакы бар, дип сөйли иде... Үлгән чакта да,

рәнҗетмәгез, авыр эшкә кушмагыз, дип үлгән... Минем бәхетсезлегемә каршыдыр инде, бичараның гомере кыска булган. Ә бусы бөеренә таянган була... Ата күркә кебек кабарына, борынын киерә, — әйтерсең бу дөнья мәңгелек ана! Карт дип санга санау юк, юньле сүз юк. Карт бай булса, адәм үләрлек көндә мине көлтәгә җибәрер идемени!

Карт ялчы яшь байдан озак зарланды. Мин ни дияргә белмәдем. Тик Әхминең рәхимсезлеге хакында ара-тирә бер-ике сүз кыстыргаладым. Бабай исә минем сүзләремә дә күп колак салмый, бер-бер артлы аһ-зарын агыза гына бирә...

Яшь бай Әхминең бу көнге бер катылыгы картның күңелен бигрәк нык рәнҗеткән...

«Төшемдә әбине — мәрхүм Шәмси карчыкны күрдем, ди, йөзе караңгы, ачулы», — ди. Гүя нәрсәдер әйтеп, Шаһины шелтәли имеш... Йокысыннан кайгырып уянган да, Гыйльман шәкертне алып барып, әбисенең кабрендә Коръән укытмакчы булган... Яшь бай җибәрмәгән:

— Син, — дип әйтеп әйтә ди, — карт җүләр, әллә акылдан шаша башладыңмы? — дип әйтеп әйтә ди. — Бер кеше кырыкка ярылырга торган мондый кызу эш өстендә, — дип әйтеп әйтә ди, — кабергә барып йөриләрмени? — дип әйтә ди. — Менә эш беткәч, теләсәң, — дип әйтеп әйтә ди, — кабердән бер дә кайтмыйча ятсаң да сүзем булмас, — дип әйтеп әйтә ди.

Карт: «Мин тиз кайтам, бер самавыр кайнап чыгарлык та вакыт үтмәс, мин кайтып килермен», — дисә дә, бай риза булмаган... Моңа каршы гомерендә кешегә сүз кайтармаган Шаһибәк байның сүзенә буйсынмаска, аның белән карулашырга итеп караган икән, яшь, һавалы бай аяк тибеп кенә кычкырган:

— Ырылдама, карт эт! Күп сөйләшә башласаң, алырсың кирәгеңне!

Боларны ишеткәч, карт ялчының әбисе дә, кабере дә башыннан чыгып очкан, күңеле беткән.

— Юк инде, бәхетле булсак, бәндәгә бәндә булмас идек, балам, — ди. — Инде, ди, картлыгым да басты, карт этне йорттан куа башладылар. Бер җылы почмак булса, чабата тугып булса да тамак туйдырыр идем, — ди. — Балакай, — ди, — алгы көн бар бит... Маңгаем сәҗдә күрми үләм бит, Ходай каршына ни йөз белән барырмын, ни җавап бирермен, — ди.

Безнең әти, эш турында каты кеше булса да, карт-корыны, ятим-җеберне бик кызганучан. Аның каршы төшмәвен исәпләп алдым да:

— Шаһи бабай, син безгә күчәр идең, безнең әткәй — картларга йомшак күңелле кеше, бездә җәй көне аз-маз эшләп, кыш тыныч ятыр идең, сиңа каты хезмәт кушмас идек, — дидем...

Карт ачык җавап бирә алмады.

— Белмим шул... ничек булыр икән соң?.. Атаң яхшы кеше инде синең, — диде...

Сүз киселде. Карт икенче якка әйләнеп ятты. Мин йокыга китә башладым.

Ләкин бу төндә миңа йокы насыйб түгел икән: инде йокыга киттем генә дигәндә, әллә өнемдә, әллә төшемдә кемнеңдер пыскып елаганына ошаш бернәрсә ишеттем. Йокым ачылды, ипләбрәк колак салсам, йөрәгемә суык йөгерде — төш түгел, өнем икән, пыскып елаучы кеше — юлдашым карт ялчы Шаһи бабай икән.

Тау артыннан сызылып таң беленә башлады. Мин йокыдан өмет өздем. Акрын гына тордым да, ерак китмәгәннәрме икән дип, атларны карап килдем.

Карт әзрәк ятсын әле, бәлки бераз йоклый да алмасмы. Һич булмаса, бераз хәл җыйсын!

Арттагы арбамнан тимер сәнәкне алдым да теге, тау астына очкан арба янына килдем.

Болытлар тарала, күк ачыла. Карт торганчы көлтәне бушатып, тәҗесен, тәртәсен бәйләп, яңадан төяп, чыгарып куярга уйлыйм.

Артык кыенлык күренми, кичә бик нык очкан төсле булса да, арбаның башка җире исән. Чыгарырга да чокыр эченнән урап юл бар. Үземнең бер арканны алдым да картның тәҗесен, тәртәсен ныгыттым.

Арбаны чыгарырлык урынга китереп, көлтәләрне яңадан төяп беткән чакта, бабай да уянып, минем янга килде: «Ай-һай, уңган җегет икәнсең, Сәфәр, ди, әллә, ди, син бер дә йокламагансың», — ди.

— Өшетте, юньләп йоклап булмады, — дим. Атлар җиктек тә кузгалдык.

Атлар хәл алганнар, төн буенча юл да бераз сүрелгән: мендерү кыен булмады.

Тауны мендерү белән, дүрт атымны бер-бер артлы тездем дә алдагы арба башына сикереп мендем. Карт миңа иярмәде, атларына утырмыйча, арба яныннан җәяүләп килә. Ул кызу йөрергә яратмый, кая ашыгасың, ди.

Мин, бабай, әйдә, дип, атларыма суктым да чаптым. Карт, чаба бир, мин акрын кайтам, дигәнен аңлатып башын селекте.

**VIII**

Бер-берсе мең сумлык бар соң бу атларның! Алты чакрым җирне фурманның өстенә өчәр рәт чыгарып төягән көлтә белән чаптырып авылга кайтып җиткән вакытта, мәзин иртә намазына азан әйтергә яңа гына манарага чыккан иде әле.

Киленнәр сыерга баралар. Акыллы карт сыерлар үзләре кайтып,

хуҗасы капка ачканны көтеп, канау буенда күшәп яталар.

Кайдандыр акрын гына гармун тавышы ишетелә. Әткәй, җиңнәрен сызганып, иртә намазына тәһарәт алып йөри. Аның йөзендә ачу күренми, кашлары да башка вакыттагы кебек салынмаган. Тәһарәт алуын бүлеп, капкадан минем атларымны җитәкләп кертеште дә!

— Нихәл, ат-арбаң исәнме? Мин берәр нәрсә ватылып ятамы икән дигән идем. Өшегәнсеңдер, атларыңны тугар да, кереп чәй эч, көлтәне мин намаздан кайткач бушатырбыз, — диде.

Ындырга барып, очланмаган солы кибәне янына атларны тугарып йортка кайтканчы кояш та чыкты.

Көн ачыла, атналар буенча туктамый, яңгыр белән йончып, өшеп беткән табигать кызарып, нурланып чыккан кояшны бәхетле елмаю белән каршы ала.

Рәхәт соң, валлаһи, көн буена туктамый җимереп эшлисең, төнен йокламый чыгасың... Көннәр шулай аяз, кояш шулай нурлы булса, тагы атналар буенча, көнен-төнен туктамый эшләргә хәзермен.

Гаҗәп уңган кеше дә инде безнең әни!

Ни арада минем кайтканны күреп калган, ни арада сыерын савып, көтүгә куган, ни арада тагы миңа самавырын кайнатып, бәрәңгеләрен пешереп өлгергән.

Өйгә килеп керсәм, самавыр гөжләп утыра, каз йомыркасы кебек эре бәрәңгеләр табак тулып, буланып торалар.

Бер чынаяк эчеп бетмәдем, урамда арба шыгырдаганы ишетелде, карасам: көлтә төягән аллы-артлы ике арба югары таба менеп баралар, алдагы күк биянең яныннан салмак кына атлап минем юлдашым Шаһи бабай бара. Чыбыркы сабын җилкә аша салып, шуның ике башыннан ике кулы белән тоткан, башын аска игән. Миңа ул нидер уйлап бара кебек тоелды...

Үткән төн күз алдымнан кичте. Аның сүзләре, миннән яшеренеп, пыскып елавы тагы йөрәгемә төште.

Ул тагы:

Бәхетле булсак, бәндәгә бәндә булмас идек! — дигән кебек булды.

Кояшның яктысы, көннең аязлыгы күренмәс булды. Самавырның гөҗләве, бәрәңгенең буланып торуы баштагы кәефләрене җуйдылар. Аннан-моннан капкаладым да, тагы әллә нинди авыр уйлар белән тышка чыгып, ындырга көлтә бушатырга киттем.